**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның «16» июленнән № 11-78

Муниципаль хезмәткәр тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибен расларга (кушымта бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек итү комиссиясе рәисенә йөкләргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е. А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2026 елның «16» июлендәге
11-78 номерлы карары белән
расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе

1. Яллаучы (эш бирүче) вәкиленә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренең башка түләүле эш башкаруы турында алдан хәбәр итүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә коррупция китереп чыгара торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба – муниципаль хезмәткәр) башка түләүле эш башкаруы турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәр, әгәр бу үз артыннан мәнфәгатьләр конфликтына китермәсә һәм, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда башкасы каралмаса, яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан язма рәвештә хәбәр итеп, башка түләүле эшне башкарырга хокуклы.

3. Муниципаль хезмәткәр башка түләүле эш башкарганда мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килгән очракта бүтән түләүле эш башкаруны туктатырга тиеш.

4. Башка түләүле эш башкаруны планлаштыручы муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә) әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә, муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе белән алдан килештерелгән тәртиптә язма рәвештә җибәрә. Күрсәтелгән хәбәрнамә башка түләүле эш башланганчы ңибәреоергә тиеш.

5. Хәбәрнамә башка түләүле эш башкару турындагы хәбәрнамәләрне теркәү журналына кергән көнне теркәлергә тиеш, журнал әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә алып барыла.

6. Хәбәрнамә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәрнамә кергән көннән өч эш көне эчендә тапшырыла.

7. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эш башкаруына каршы килсә, хәбәрнамә бланкында ул муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эше мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин дигән фикерен нигезли.

8. Яллаучы (эш бирүче) вәкилендә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында шик туган очракта, муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамәсе өч көн эчендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы Нигезләмә нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә карау өчен җибәрелә.

9. Башка түләүле эш башкару графигы, шулай ук мондый эшне башкару белән бәйле башка йөкләмәләр үзгәргән очракта, муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә әлеге Тәртип нигезендә хәбәр итә.

Татарстан Республикасы «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибенә
1 нче кушымта

______________________
(танышу турында тамга)

______________________________
(яллаучы (эш бирүче) вәкиленең ФИА)
кемнән:

_________________________________
(муниципаль хезмәткәр вазыйфасын биләүченең ФИА)

Башка түләүле эш башкару турында
ХӘБӘРНАМӘ

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә мин 20_______ елның «______» _____________ түбәндәге түләүле эшчәнлекне үтәргә җыенам: ___________________________________________________________
(эшчәнлек төрен күрсәтергә: педагогик, фәнни, иҗади яки башка эшчәнлек)
буенча_____________________________________________________________________
(хезмәт килешүе, граждан-хокукый шартнамәсе, авторлык килешүе һ. б.)
_____________________________________________________________________
(башка түләүле эш башкарыла торган оешманың тулы исеме һәм әлеге оешманың адресы)
_______________________________________________________________
(башкарыла торган эшнең характерын күрсәтү, мәсәлән, «студентларны укыту», «мәкаләләр язу» һ.б.)
Эш мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүгә китермәячәк.

«____» __________ 20___ел ___________________ __________________
(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаның расшифровкасы)

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

______________________________________ ________________________
(хәбәрнамәне килештерүче вазыйфаи затның вазыйфасы, ФИА) (имза, дата)

Журналда теркәлү номеры
Башка түләүле хезмәт үтәү турында хәбәрнамәләрне теркәү номеры ______
Хәбәрнамәне теркәү датасы «______» ______________ 20___ ел.

__________________________________ (хәбәрнамәне теркәгән вазыйфаи затның ФИА)

__________________________ (хәбәрнамәне теркәгән вазыйфаи затның имзасы)

Татарстан Республикасы «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибенә
2 нче кушымта

Башка түләүле эш башкару турында
хәбәрнамәләрне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № т/б | Хәбәрнамәне биргән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А. | Хәбәрнамәне биргән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы | Хәбәрнамәне теркәү датасы | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге (эшчәнлек характеры), башка түләүле эш башкарылачак оешма атамасы | Хәбәрнамәне кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А., имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |